**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы**
**Түбән Табын авыл җирлегенә керүче Түбән Табын авылы**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№ 2** **06.12.2019 ел**

***Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлеге составына керүче Түбән Табын торак пунктына 2020 нче елда гражданнарның үзара салымын кертү турында***

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Түбән Табын торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән Табын торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 нче елда, I группадагы инвалидлардан тыш, 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:
- Түбән Табын авылында җәйге чорда юлларны карау
- Түбән Табын авылында кышкы чорда юлларны карау, чистарту
- Түбән Табын авылында урам утларын карау һәм ремонтлау
- Түбән Табын авылында юлларны карау, ремонтлау
- Түбән Табын авылында иске агачларны кисү
- Түбән Табын авылы территориясен чүп үләннәреннән чистарту
- Түбән Табын авылында янгынга каршы чаралар
- Җирлектә бәйрәм чараларын оештыру, уздыру, бүләкләр алу
- Җирлектәге һәйкәлләрне ремонтлау
- Тукталыш төзү

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда , Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы, Югары Табын авылы, Тукай урамы, 19б йорт; Түбән Табын авылы, Мәктәп урамы, 48в йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

*Гражданнар җыенында рәислек итүче,*
*Түбән Табын авыл җирлеге башлыгы* *Р.Ш. Кыяметдинов*